ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧУРАКАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423746, Чуракай авылы,
Совет ур., 69 нчы йорт.
Тел.3-44-65

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА ЧУРАКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423746, село Чуракаево,
ул. Советская,дом 69,
Тел. 3-44-65

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.11. 2019 г. № 1

Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлегенең Чуракай, Иске Әгъбәз торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Чуракай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Чуракай авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. 2019 елның 27 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Чуракай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. 2019 елның 28 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Иске Әгъбәз торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

- юлларны ремонтлау һәм карап тоту (грейдерлау,кардан чистарту);
- Чуракай, Иске Әгъбәз авылларында урам утлары чыгымнарын тәэмин иту;
-Чуракай авылында су торбаларын алыштыру, **с**у чыганакларын рэсмилэштеру;
-Чуракай, Иске Әгъбәз авылы зиярат җирләрен рәсмиләштерү
- Зиярат ихаталарын коймалап бетерүне хәл иту

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

3. Халык җыенын түбәндәге адреслар буенча үткәрергә:

Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Чуракай авылы, Совет урамы, 69 йорт.

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Әгъбәз авылы, Ленин урамы, 53 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Чуракай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хайдаров